Татар теленә өйрәтү өчен эш программасына аннотация/
Аннотация к рабочей программе по обучению родному языку

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус телле балаларны татарчага, татар телле балаларны ана теленә өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды. Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга һәм 2 яшьтән 7 яшькә кадәр булган татар телле балаларның ана телен өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларында (Л. С. Выготский, П. Я. Гальперин, В. В. Давыдов, Е.А. Пассов) чагылыш тапкан фәнни тикшеренүләргә, гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

Балалар бакчасында татар теленә өйрәтү программасы (алга таба программа) түбәндәге төп документларга нигезләнеп төзелде:

1. «Россия Федерациясенең мәгариф турындагы федераль законы” (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 29.12.2012 елның №273-ФЗ карары нигезендә расланган)
2. “Федераль дәүләт мәгариф стандартлары” (алга таба ФДМС) (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 17 октябре, №1155 карары нигезендә расланган)
3. “Татарстан республикасының Мәгариф турындагы законы” (2013 елның 28 июнендә кабул ителгән)
4. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасының башка телләре турында” Татарстан Республикасы Законы(08.07.1992 N 1560-XII)
5. Татарстан Республикасының 2010-2015 елларга “Киләчәк”мәгариф усеш стратегиясен раслау турында (2010 елның 30 декабрендә №1174)
6. Мәктәпкәчә белем бирү ФДМСна белешмәләр(Россияның фән һәм мәгариф министрлыгы методик тәкъдимнәре 28.02.2014 ел №08-249)
7. СанПин 2.4.1.2731-10; Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибы (20.12.2010 ел №164) карары нигезндә , Россия Мнюстендә расланган

(22.12.2010 №19342) “Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эш режимы оештыруга, аның төзелешенә һәм эчтәлегенә санитар-эпидемиологик таләпләр” «№1 Үзгәреш” 2.4.1.2660-10

8. Балалар бакчасының Уставы.

Татар телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү өчен, балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру, сюжетлы уеннар оештыру, гомумән, баланың актив сөйләмен үстерү зарур. Сөйләшергә өйрәтү өчен баланы мөмкин кадәр күбрәк аралашуга җәлеп итәргә кирәк. Мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең гомуми белем бирү программасы төзелешенә яңа федераль белем бирү стандартлары буенча татар теле эшчәнлегенә бирелгән сәгатьләр санын бүлгәндә сөйләм телен үстерүгә күбрәк игътибар итү сорала.
Белем бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең эше дә көннән-көн яңара, матур традицияләргә байый. Педагоглар яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем бирүнең нәтиҗәле методларын эзлиләр, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә, педагогик тәҗрибәсенә ныграк таяналар. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә зур игътибар бирелә.
“Татарча сөйләшәбез” һәм “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик комплектлар балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. Комплектка, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, методик кулланма,күрсәтмә һәм таратма әсбаплар, аудио- һәм видеоматериаллар, балалар өчен эш дәфтәрләре туплап бирелгән. “Татарча сөйләшәбез” методик комплектлары өч яшь төркеме (уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәре) өчен әзерләнде. Ә“Туган телдә сөйләшәбез”методик комплеклары 2 яшьтән 7 яшькә кадәр балаларны үз эченә ала. Бүгенге социолингвистик ситуациядә һәм гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары тормышка ашу кысаларында рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү буенча яңа укыту-методик кулланмалар эшләү зарурлыгы килеп басты.

Билгеле булганча, телгә өйрәтүнең максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү.

Рус телле балаларга татар теле өйрәтү максаты киңкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

Балаларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, балалар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

Программаның максаты: Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу,балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

Программаның бурычлары:
1. Сүз байлыгы булдыру, аны баету, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Диалогта катнаша белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен камилләштерү.

Көтелгән нәтиҗә.
Татар телен өйрәнүче рус телле балаларның сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы күздә тотыла:
- өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага,раслый белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча тәрбиячененң сорауларына жавап һәм сораулар куя белү;
- бирелгән үрнәк диалоглар буенча охшаш диалоглар төзү, әңгәмәдә катнаша алу;
- терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү.

Рус телле балаларга татар теле 4 яшьтән өйрәтелә башлый.Укыту-методик кулланма нигезендә һәр яшь төркеме өчен лексик минимум билгеләнгән

УКЫТУ-МЕТОДИК КУЛЛАНМА (УМК “МИНЕМ ӨЕМ”) НИГЕЗЕНДӘ МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮЧЕ РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЛЕКСИК МИНИМУМ, 4-5 ЯШЬ.

СҮЗЛӘР	САНЫ
ЛЕКСИК МИНИМУМ (4-5 яшь) **Актив сүзләр:** эти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 сүз) **Пассив сүзләр:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз)	**62 сүз**

УКЫТУ-МЕТОДИК КУЛЛАНМА (УМК “УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘБЕЗ”) НИГЕЗЕНДӘ МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮЧЕ РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЛЕКСИК МИНИМУМ, 5-6 ЯШЬ.

СҮЗЛӘР	САНЫ
Актив сүзләр: эти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак,	**4-5 яшь** **62 сүз**

куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш. (49 сүз) **Пассив сүзләр:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз)	
+ ЛЕКСИК МИНИМУМ (5-6 яшь) **Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз) **Пассив сүзләр:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз)	**5-6 яшь** **45 сүз**
Барлыгы	**107**

УКЫТУ-МЕТОДИК КУЛЛАНМА
(УМК “БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР – МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР”) НИГЕЗЕНДӘ
МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮЧЕ
РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЛЕКСИК МИНИМУМ, 6-7 ЯШЬ.

СҮЗЛӘР	САНЫ
Актив сүзләр: әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш. (49 сүз) **Пассив сүзләр:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз)	**4-5 яшь** **62 сүз**
+ ЛЕКСИК МИНИМУМ (5-6 яшь) **Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз) **Пассив сүзләр:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз)	**5-6 яшь** **45 сүз**
Актив сүзләр: син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр, нәрсә яратасың?(пассив сүз)	**6 -7 яшь** **60 сүз**
Барлыгы	**167 сүз**

Ана телен өйрәнүче татар балаларның сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы күздә тотыла:

Федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалашу:физик яктан үсеш алган, кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә- тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомумкабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштергән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар

нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең нигезләрен үзләштергән бала шәхесе.

№	Белем бирү өлкәләре	Эшчәнлек төрләре	Бурычлар
1.	Социаль-аралашу үсеше	- ситуатив күнегүләр - сюжетлы-рольле уеннар - әңгәмәләр	өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
2.	Танып-белү үсеше	- экскурсияләр - дәфтәрләрдә эш -предметларны санау,төсен, формасын, зурлыгын әйтү	Туган як табигате, үсемлекләре, җәнлекләре белән танышу; предметларның төсен,зурлыгын, формасын дөрес әйтә белү; экологик культура, табигатькә аңлы караш тәрбияләү
3.	Сөйләм үсеше	- әкиятләр сәхнәләштерү - хикәяләр төзү - шигырьләр уку - мультфильмнар карау - әңгәмәләр	Нәфис сүз, халык авыз иҗаты, әдәби әсәрләр, милли бәйрәмнәр аша балаларның сөйләм телен баету, уй-фикерләрен билгеле бер эзлеклелектә җиткерә белүләренә ирешү
4.	Нәфис-нәфасәти үсеш	- җырлар - музыкаль-дидактик уеннар - җырлы-биюле уеннар - драма уеннары - дәфтәрләрдә эш	Балаларның милли сынлы сәнгать турындагы белемнәрен баету, татар һәм Идел буе халыкларының декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре белән таныштыру, милли орнамент белән кием-салым, савыт-саба бизәргә өйрәтү; күренекле композиторларның, төрле халыкларның җырлары, биюләре, музыкаль инструментлары белән танышу.
5.	Физик үсеш	- хәрәкәтле уеннар - зиһен сынаш уеннары - җырлы-биюле уеннар	Идел буе халыкларының хәрәкәтле уеннары аша балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту

Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар.

1. Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.
2. Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).
3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек(таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.
4. Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).
5. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар).
6. Интерактив уеннар.
7. Эш дәфтәрләре.

Эш төрләре һәм формалары.

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу;
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог;
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып);
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына); 6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, "Командир" уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары;
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр;
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү;
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу);
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү;
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау;
12. Интерактив уеннар.